**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЯШЕЛ ҮЗӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ОЛЫ АЧАСЫР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

**КАРАР**

2021 елның 9 июле №47

Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районы Олы Ачасыр авыл җирлеге Советының 2019 елның 13 ноябрендәге 224 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районы Олы Ачасыр авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында (2020 елның 9 апрелендәге 236 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән)

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районы «Олы Ачасыр авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районы Олы Ачасыр авыл җирлеге Советы **карар итте**:

1. Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районы Олы Ачасыр авыл җирлеге Советының 2019 елның 13 ноябрендәге 224 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районы Олы Ачасыр авыл җирлеге торак пунктларында гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәгә (2020 елның 9 апрелендәге 236 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. киләсе эчтәлектәге 1.7.1 пункты белән тулыландырырга:

1.7.1. Гражданнар җыены торак пункт территориясе өлешендә торак пункт территориясенең әлеге өлешендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча үткәрелергә мөмкин.

Гражданнар җыены үткәрелә торган торак пункт территориясенең бер өлеше чикләре, җирле әһәмияттәге тиешле мәсьәләне хәл иткәндә, торак пункт территориясенең күрсәтелгән өлешендә яшәүчеләрнең гомуми мәнфәгатьләре критериеннән чыгып, муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы тарафыннан билгеләнә.

1.2. 3.5 пунктта «торак пунктта яшәүчеләр» сүзләреннән соң «(яисә аның территориясенең бер өлеше)» сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге карарны Интернет челтәренең Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре составындагы Яшел Үзән муниципаль районы мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru), шулай ук Олы Ачасыр авыл җирлеге мәгълүмат стендларында: Олы Ачасыр авылы, Үзәк урамы, 46 йорт (җирлек хакимияте бинасы), Олы Ачасыр авылы, Кооператив урамы, 26 йорт (авыл мәдәният йорты бинасы) урнаштырырга.

**Олы Ачасыр авыл жирлеге башлыгы, Совет рәисе** **М.Г. Гатиятуллин**